Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Кукмара шәһәре Советы

КАРАР

2018 елның 17 сентябре № 18

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Уставы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга

2. «Кукмара шәһәр тибындагы поселогында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында» 2007 елның 24 февралендәге 5 номерлы Кукмара поселогы Советының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Кукмара ш. МБ» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев